| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2026 ел Кукмара ш. № 35

Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (2022 елның 24 августындагы 137 номерлы, 2025 елның 29 июлендәге 320 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 8 статьяның 9 пунктындагы 4 енче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, рәсми рәвештә басылган көннән үз көченә керә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев